ЯКШӘМБЕ
4 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 28 (5828)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Ярышта беренчелек өчен

Шушы көннәрдә, авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсеүзенеңэшен тәмамлады.

Киңәшмәдә 1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары, 1940 нчы елгы бурычлар турындагы, Татарстан, Чувашстан һәм Мордовия республикалары арасында социалистик ярыш оештыру турындагы мәсьәләләр тикшерелде.

Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышуларда катнашкан барлык ораторлар партиянең XVIII нче съезды тарафыннан авыл хуҗалыгы алдына куелган бөек бурычларны: югары иген уңышы алу өчен, терлекчелек проблемасын өченче бишьеллыкта тулысынча хәл итү өчен бездә мөмкинлекләрнең гаять зур икәнлеген әйттеләр һәм шул мөмкинлекләрдән файдалану нигезендә 1940 нчы елда тагын да зуррак нәтиҗәләргә ирешү өчен ничек көрәшергә кирәклекне гүзәл мисаллар һәм фактлар белән күрсәтеп үттеләр.

1939 нчы елда, республикабызда һава шартлары беркадәр начар булуга карамастан, күп кенә колхозлар узган елны югары уңыш яулап алдылар. Алар менә хезмәтне дөрес оештыру, социалистик ярышны киң җәелдерү, агротехника чараларын яхшы итеп үткәрү, колхозчылар арасында политик-агитация эшләрен үрнәк рәвештә оештыру нигезендә ирештеләр.

Әтнә районы, Ленин исемендәге колхозның иптәш Җәббаров җитәкчелегендәге бригадасы республикабыздагы колхозларга үрнәк булырлык. Иптәш Җәббаров бригадасы 1939 нчы елны бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 14,32 центнер уңыш алды.

Бу бригаданың, һәм гомумән, Ленин исемендәге бу колхозның колхозчылары 1940 нчы елгы уңыш өчен көрәшне җәелдерделәр. Язгы чәчүгә хәзерлектә Әтнә районында бу колхоз беренче урыннарның берсен алып тора.

Киңәшмәдә катнашкан башка бик күп иптәшләр дә, гүзәл һәм чын-чыннан большевистик эшләр турында сөйләделәр. Алар барсы да „уңыш яулап алына ул“, „без аны яулап алырга тиешбез һәм алырбыз“ дигән төп фикерне чагылдырдылар һәм шуңа республикабызның барлык колхозчыларын чакырдылар.

Киңәшмә республикабызның барлык район, колхоз җитәкчеләренә, җир органнары работникларына мөрәҗәгать итеп, колхозларда хезмәтне дөрес оештыру мәсьәләләренә, эшне звенолап оештыруга зур игтибар итәргә чакырды. Илебездә югары иген уңышы яулап алу өчен зур яңалыклар кертеп, рекордлы нәтиҗәләр биргән ефремовчыларның һәм республикабыздагы алдынгыларның тәҗрибәсе колхозларда звенолап эшләүнең нинди өстенлекләр биргәнлеген, хезмәт дисциплинасын тагын да ныгытканлыгын, колхозчыларның иҗади инициативасын үстерүгә гаять зур ярдәм иткәнлеген бик ачык итеп күрсәтә. Киңәшмәнең мөрәҗәгатендә:

— Кадерле вакытны әрәм итмичә, даими звенолар төзүгә хәзердән үк керешергә, һәрбер звеноga чәчү участкысы беркетергә, һәрбер звено буенча агротехника чаралары планы төзергә һәм аларны үтәүгә керешергә кирәк. Звено җитәкчеләре итеп иң яхшы стахановчы колхозчыларны, югары уңыш мастерларын билгеләргә кирәк. Язгы чәчүгә хәзерләнүне хезмәтне звенолап оештыру системасы нигезендә үткәрергә кирәк, диелә.

Барлык агрономнарның, галимнәрнең һәм авыл хуҗалыгының башка белгечләренең бөтен көчләреннән дөрес файдалануның Сталинчыл уңыш өчен көрәштә, терлекчелекне тагын да алга җибәрүдә бик зур урын тотканлыгын күрсәтеп, киңәшмә аларга мөрәҗәгать итте.

Һич шик юк, республикабызның авыл хуҗалыгы белгечләре бу чакыруга практик эш белән һәм бик зур күтәренкелек белән җавап бирерләр.

Киңәшмә республикабызның барлык колхозчылары, МТС, совхоз эшчеләре исеменнән бөтен Союз күләмендәге йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылды, һәм кардәш республикалар—Чувашстан, Мордовия республикалары белән социалистик ярышка чыгарга карар бирде. Урыннардагы партия, совет, комсомол, профсоюз оешмаларының иң мөһим бурычларыннан берсе: республика алдынгылары киңәшмәсенең материалларын барлык колхозчыларга, колхозчы хатын-кызларга, МТС эшчеләренә, белгечләренә яхшы итеп аңлатудан һәм шуның нигезендә 1940 нчы елның язгы чәчүенә хәзерлектә булган бөтен житешсезлекләрне бик тиз бетереп, чәчүгә большевистик хәзерлекне тәэмин итүгә, терлекчелек планын сан һәм сыйфат ягыннан тулысынча үтәүгә ирешү өчен көрәшкә киң массаны туплаудан гыйбарәт.

Быел, 25 нче июньдә орденлы Татарстан үзенең 20 еллыгын бәйрәм итә. Бу бөек бәйрәмне лаеклы рәвештә каршы алу—республикабыздагы һәрбер хезмәт иясенең намус эше. Алдынгылар киңәшмәсе республикабызның барлык колхозчыларын, МТС һәм совхоз эшчеләрен бу бәйрәмне производствода зур уңышлар белән истә калдырырга чакырып болай диде:

„Без сезне ТАССР ның данлыклы XX еллыгын язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп хәзерләнү һәм аны яхшы итеп үткәрү белән, йөз пот уңыш өчен көрәштә хәл иткеч уңышлар белән каршыларга чакырабыз“.

Бу чакыру республикабызның барлык колхозларында һәм совхозларында алкышлап каршы алыныр һәм Татарстанның XX еллыгы исемендәге социалистик ярышка барлык бригадалар, колхозлар, совхозлар, МТС лар бердәм рәвештә кушылырлар һәм шуның нигезендә 1940 нчы елда авыл хуҗалыгы алдында торган бөек һәм катлаулы бурычлар уңышлы рәвештә хәл кылыныр.

Әйдәгез, иптәшләр, социалистик ярыш байрагын тагын да югарырак күтәрик!

Ленинград Хәрби Округы Штабының юкка чыгаруы

1) СССР дошманнарының сатып алынган агентлары чит илләр матбугатында „фин самолетлары СССР районнарына рейд үткәрделәр һәм Кронштадтта Советның хәрби карабларын бомбага тоттылар, караблар яна“ һәм башка шундыйлар турында хәбәрләр тараталар. Штаб, бу хәбәрләрнең барсының да тоташ уйдырмадан гыйбарәт икәнлеген белдерә. Фин авиациясе „Англиядән, Франциядән, АКШ тан, Швециядән, Италиядән иң яңа самолетлар алды“, шуңа карамастан, ул „рейд“ үткәрмәде генә түгел, бәлки **Лахтида, Равиниемида, Сартовалада, Выборгта** фин штабларының команда пунктларын сакларга да сәләтсез булып чыкты, бу пунктлар Совет авиациясе тарафыннан җимерелделәр. СССР районнарында Кронштадтка таба яки нинди дә булса башка якка фин авиациясенең бер нинди рейды да булмады һәм булырга да мөмкин түгел иде.

2) СССР дошманнарының шул ук ялланган агентлары чит илләр матбугатында „Карелия бугазында һәм Ладогадан төньяктарак булган районда совет гаскәрләренең зур һөҗүме башланды, бу һөҗүмнең перспективалары әле ачык түгел“ дип раслыйлар. Штаб бу раслауларның да шулай ук һичбер нигезсез икәнлеген белдерә. Чынында Карелия бугазында һәм Ладогадан төньякка табарак булган районда бары тик берничә ротаның җирле характердагы вак бәрелешләре генә бар, бу бәрелешләр озакка сузылмый торган артиллерия атышуы белән бергә алып барыла. Европада көнбатыш фронттагы операцияләрнең микроскоп күләмендә булуы карашыннан берничә ротаның бәрелешүе „зур һөҗүм“ булып күренәдер, ихтимал. Ләкин безгә мондый күләмнәр көлке булып күренәләр һәм без берничә ротаның бәрелешүен зур һөҗүм дип тә, кечкенә һөҗүм дип тә саный алмыйбыз.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

2 нче февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның хәрби объектларын уңышлы рәвештә бомбага тотты. Һава сугышларында дошманның 11 самолеты бәреп төшерелде. Безнең авиациядән 1 самолет үз аэродромына кайтмады.

Дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары

Сарыклар, кәҗәләр санын тагын да арттыру һәм йонның сыйфатын яхшырту белән колхозларда тагын да күбрәк кызыксыну тудыру өчен ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты **карар бирәләр:**

1. Дәүләткә йон тапшыруны колхозларда чынлыкта булган сарыклар, кәҗәләр һәм дөяләр саны буенча исәпләүдән гыйбарәт булган хәзерге системаны бетерергә һәм 1940 нчы елдан башлап колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыруларын колхозларга беркетелгән җир мәйданының (сөреләә торган җирләрнең, шул исәптән җимеш һәм түтәл бакчаларының, болыннарның һәм көтүлекләрнен)һәр гектарыннан исәпләүне билгеләргә.

2. 1941 нче елдан башлап республикаларда, крайларда һәм өлкәләрдә, колхозларга беркетелгән җир мәйданының (сөреләә торган җирләрнең, шул исәптән җимеш һәм түтәл бакчаларының, болыннарның һәм көтүлекләрнең) 1 гектарыннан, колхозларның дәүләткә йон тапшырулары буенча түбәндәгечә уртача еллык нормаларны билгеләргә (ярым тупас йон, грамнар белән), ә 1940 нчы елга, шушы карар гамәлдә булган беренче ел өчен, кимрәк нормалар билгеләргә.

	Ярым тупас йон граммнар белән 1941 е.	1940 е.
I. Архангельск өлкәсе, Вологда өлкәсе, Ленинград өлкәсе, Калинин өлкәсе, Москва өлкәсе, Ярославль өлкәсе, Иваново өлкәсе, Горький өлкәсе, Коми АССР, Киров өлкәсе, Удмуртия АССР, Пермь өлкәсе, Свердловск өлкәсе, Хабаровск крае, Приморье крае	40	25
II. Белоруссия ССР, Смоленск өлкәсе, Орел өлкәсе, Тула өлкәсе, Рязань өлкәсе, Пенза өлкәсе, Мордовия АССР, Чуваш АССР, Мари АССР, Казагстан ССР	70	50
III. Курск өлкәсе, Тамбов өлкәсе, Саратов өлкәсе, Волга буе немецләре АССР, Куйбышев өлкәсе, Татарстан АССР, Башкыртстан АССР, Чечин-ингушия АССР, Новосибирск өлкәсе, Иркутск өлкәсе, Чита өлкәсе	120	100
IV. Украина ССР, Воронеж өлкәсе, Сталинград өлкәсе, Чкалов өлкәсе, Чиләбе өлкәсе, Омск өлкәсе, Бурәт-Монголия АССР	180	140
V. Краснодар крае, Әрмәнстан ССР, Азербәйҗан ССР, Калмык АССР, Таҗикстан ССР, Алтай крае, Красноярск крае	300	250
VI. Ростов өлкәсе, Дагстан АССР, Кыргызстан ССР	450	400
VII. Кырым АССР, Кабардино-Балкария АССР, Төньяк Осетия АССР, Грузия ССР, Үзбәкстан ССР	550	500
VIII. Орджоникидзе крае, Төркмәнстан ССР	700	600

Яшелчә хуҗалыгы нык үскән Москва һәм Ленинград шәһәрләре тирәсендә 50 километр ераклыкта һәм Киев, Харьков, Сталино, Днепропетровск, Ростов-Дон, Горький, Иваново, Баку, Свердловск һәм Чиләбе шәһәрләре тирәсендә 25 километр ераклыкта урнашкан колхозларда дәүләткә йон тапшыруны сарыкларның һәм кәҗәләрнең 1 нче январьга чынлыкта булган санына карап 1939 нчы елгы нормалар буенча исәпләү тәртибен саклап калырга.

3. 1940 нчы елдан башлап колхозчы йортларыннан һәм ялгыз хуҗалыклардан дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру буенча тиешле елның 1 нче январена чынлыкта булган барлык яштәге сарыкларның, кәҗәләрнең һәм дөяләрнең һәрбер башыннан грамм исәбеннән түбәндәге еллык нормаларны билгеләргә:

РЕСПУБЛИКАЛАР, КРАЙЛАР һәм ӨЛКӘЛӘР	Колхозчы йортлары: сарыклар	Колхозчы йортлары: кәҗәләр	Ялгыз хуҗалыклар: сарыклар	Ялгыз хуҗалыклар: кәҗәләр
I. Архангельск өлкәсе, Вологда өлкәсе, Ленинград өлкәсе, Мурманск өлкәсе, Приморье крае, Хабаровск крае, Коми АССР, Карелия АССР, Якутия АССР	200	130	500	150
II. Горький өлкәсе, Иваново өлкәсе, Калинин өлкәсе, Киров өлкәсе, Москва өлкәсе, Пермь өлкәсе, Ярославль өлкәсе, Белоруссия ССР	300	130	600	150
III. Орел өлкәсе, Рязань өлкәсе, Свердловск өлкәсе, Смоленск өлкәсе, Тула өлкәсе, Дагстан АССР, Мари АССР, Удмуртия АССР, Чуваш АССР, Таҗикстан ССР	400	180	600	200
IV. Курск өлкәсе, Омск өлкәсе, Пенза өлкәсе, Тамбов өлкәсе, Кабардино-Балкария АССР, Мордовия АССР, Төньяк Осетия АССР, Чечен-Ингушия АССР	500	180	750	200
V. Алтай крае, Воронеж өлкәсе, Иркутск өлкәсе, Куйбышев өлкәсе, Красноярск крае, Новосибирск өлкәсе, Чиләбе өлкәсе, Чита өлкәсе, Башкыртстан АССР, Бурят-Монголия АССР, Татарстан АССР, Әрмәнстан ССР	600	200	800	220
VI. Саратов өлкәсе, Чкалов өлкәсе, Азербәйҗан ССР, Үзбәкстан ССР	750	200	950	220
VII. Краснодарь крае, Сталинград өлкәсе, Волга буе немецләре АССР, Украина ССР, Грузия ССР, Кыргызстан ССР, Казагстан ССР	900	200	1.200	220
VIII. Орджоникидзе крае, Ростов өлкәсе, Калмык АССР, Кырым АССР, Төрекмәнстан ССР	1.100	200	1.400	220

Ике үргәчле бер баш дөядән мәҗбүри рәвештә йон тапшыру нормаларын түбәндәгечә билгеләргә:
колхозчы йортларыннан—2.400 грамм.
ялгыз хуҗалыклардан—2.700 грамм, ә бер үргәчле бер баш дөядән колхозчы йортларыннан—1.500 грамм.
ялгыз хуҗалыклардан—1.800 грамм.

4. Союзный һәм автономияле республикаларның Совнаркомнарын, край һәм өлкә башкарма комитетларын,—дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру буенча республикалар, крайлар һәм өлкәләр өчен расланган нормалар нигезендә, колхозлар, колхозчы йортлары, ялгыз хуҗалыклар тарафыннан дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру буенча районнар өчен еллык нормалар билгеләргә һәм аларны, СССР Наркомзагы раслаганнан соң, 1940 нчы елның 1 нче мартына иглан итәргә мәҗбүр итәргә.

5. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру буенча СССР Наркомзагында колхозлар өчен расланган район нормаларын, кагыйдә буларак, райондагы барлык колхозларга карата кулланырга. Аерым хәлләрдә, кайбер колхозлар өчен, дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру буенча районнарга карата билгеләнгән еллык нормаларны, СССР Наркомзагының өлкәләрдәге, крайлардагы һәм өлкәләргә бүленми торган республикалардагы уполномоченныйларының раславыннан соң, 50 процентка кадәр арттырырга яки киметергә рөхсәт итәргә, ләкин йон тапшыру буенча район өчен расланган еллык норма уртача алганда әлбәттә үтәлгән булырга тиеш.

6. СССР Наркомзагына, шушы карар гамәлдә булуның беренче елында (1940 нчы елны), кайбер хәлләрдә колхозларга йон тапшыру буенча исәпләнгән 1 килограмм йон урнына тере үлчәвендә 5 килограмм ит тапшырырга рөхсәт итү хокукын бирергә.

7. Промысло һәм балыкчылык артельләренең, инвалидлар кооперациясе артельләренең авыл җирләрендә һәм дача җирләрендә торучы членнары, шулай ук дәүләт һәм кооператив предприятиеләрендә сезонлы эштә булмыйча, даими эштә эшләүче һәм үз файдалануларында сарыклары, кәҗәләре һәм дөяләре булган эшчеләр һәм хезмәткәрләр дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыруга тартылалар дип билгеләргә:

а) әгәр дә аларның файдалануында терлекләр саны авыл хуҗалыгы артеле уставында шул районның колхозчылары өчен билгеләнгән саннан артык булмаса,—шул райондагы колхозчы йортлары өчен билгеләнгән нормалар буенча;

б) әгәр дә аларның файдалануындагы терлекләр саны авыл хуҗалыгы артеле уставында шул районның колхозчылары өчен билгеләнгән саннан артык булса,—ялгыз хуҗалыклар өчен билгеләнгән нормалар буенча;

в) обязательстволар тапшырылган вакытта сезонлы эштә яки даими эштә бер елдан ким эшләгән ялгыз хуҗалыкчылар дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыруга шул райондагы ялгыз хуҗалыкчылар өчен билгеләнгән нормалар буенча тартылалар.

8. Авыл җирләрендә һәм дача җирләрендә торучы һәм үз файдалануларында сарыклары, кәҗәләре һәм дөяләре булган ялгыз кустарьлар дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыруга шул райондагы ялгыз хуҗалыклар өчен билгеләнгән нормалар буенча тартылалар.

9. СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының „Колхозларда җәмагать терлекчелеген үстерү чаралары турында“ 1939 нчы елның 8 нче июлендә чыгарган карарының 27 нче пункты нигезендә, ит тапшыруга тартылмаучы хуҗалыклар дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыруга тартылмыйлар дип билгеләргә.

10. Дәүләткә йон тапшыру буенча йон тапшыруның еллык нормасына карата процентлар белән түбәндәге соңгы срокларны билгеләргә:

1 нче срок—60 процент күләмендә, 1 нче августтан соңга калмыйча;

2 нче срок—40 процент күләмендә, 15 нче ноябрьдән соңга калмыйча.

11. Колхозлар, колхозчы йортлары, ялгыз хуҗалыклар, эшче һәм хезмәткәр хуҗалыклары түбәндә күрсәтелгән йоннарны тапшырсалар обязательствода күрсәтелгән бер килограмм йонны тапшырган дип исәпләнәчәкләр (граммнар белән):

меринос һәм цыгай нәселле сарык йоны . . . . 900 грамм
ярым тупас метис сарык йоны һәм тупас йонлы токымнардан — каракүл, смушковый, романовский, тушин, гиссар, колундин токымындагы сарыклардан һәм бу токымнарның метисларыннан алынган йон, шулай ук дөя йоны һәм ялы . . . . 1000 „
сарыкларның башка төрле тупас йонлы токымнарыннан алынган йон 1100 „
кәҗә йоны . . . . 1500 „
беренче тараудан алынган кәҗә мамыгы . . . . 75 „
2 нче „ „ . . . . 100 „
кәҗәнең җабага мамыгы . . . . 150 „

12. Аерым буларак, 1940 нчы ел өчен Казагстан, Кыргызстан һәм Төркмәнстан ССР районнарындагы колхозларда (бу республикаларда СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел 4 нчы ноябрьдә чыгарган 1887 нче номерлы карары нигезендә мәҗбүри рәвештә ит тапшыру терлекләр саны буенча билгеләнә), шулай ук Мурманск өлкәсе, Карелия һәм Якутия АССР колхозларында һәм Ерак Төньяк районнарында дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру 1939 нчы елны гамәлдә булган нормалар буенча 1940 нчы елның 1 нче январена чынлыкта булган сарыклар, кәҗәләр һәм дөяләр саныннан чыгып исәпләнә.

13. Йон тапшыруга дөрес тартылмау турындагы жалобалар обязательстволар тапшырылган көннән башлап 10 көн срок эчендә СССР Наркомзагының район уполномоченныйларына бирелә дип билгеләргә.

Райуполнаркомзагның карары өстеннән бу карар тапшырылган көннән башлап 10 көн срок эчендә район башкарма комитетына жалоба бирергә мөмкин.

Әгәр дә район башкарма комитеты жалобаны урынлы дип тапса, үзенең карарын Наркомзагның өлкәдәге, крайдагы, өлкәләргә бүленми торган республикадагы уполномоченныеның раславына кертә һәм бу соңгысының карары актык карар була.

14. Түбәндәге карарларны гамәлдән чыккан дип санарга:

а) „Дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында һәм 1933 нче елны йон хәзерләү планы турында“ СССР Совнаркомының 1933 нче ел 10 нчы март карары (СССР ның законнар җыентыгы 1933 нче ел, № 18, ст. 101);

б) „1934 нче елны дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында“ СССР Совнаркомының 1934 нче ел 15 нче январь карары (СССР ның законнар җыентыгы 1934 нче ел, № 4, ст. 34);

в) „1935 нче елны дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында“ СССР Совнаркомының 1935 нче ел, 23 нче январь карары (СССР ның законнар җыентыгы, 1935 нче ел, № 11, ст. 85);

г) „Нечкә йонлы сарыкчылыкны үстерү буенча дәүләт планы һәм колхозчыларга үз файдалануларында сарыклар булдыруда ярдәм итү турында“ СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1936 нчы ел 7 нче март карарының IV нче бүлегенең 1, 2, 3 һәм 4 нче пунктлары (СССР ның законнар җыентыгы, 1936 ел, № 15, ст. 128);

д) „1936 нчы елны дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында“ СССР Совнаркомының 1936 нчы ел 19 нчы апрель карары (СССР ның законнар җыентыгы, 1936 нчы ел, № 22, ст. 203);

е) „1937 нче елны дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында“ СССР Совнаркомының 1937 нче ел 16 нчы февраль карары (СССР ның законнар җыентыгы, 1937 ел, № 15, ст 47);

ж) „1938 нче елны мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында“ СССР Совнаркомы янындагы Экономсоветның 140 нчы номерлы 1938 нче ел 3 нче март карары;

з) „1939 нчы елны дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында“ СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел 27 нче январь карары.

СССР Халык Комиссарлары Советы председателе
В. МОЛОТОВ.

ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре
И. СТАЛИН.

30 январь, 1940 ел.

„СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧЫНЫҢ ГЕРОИК ХӘРӘКӘТЕНДӘ КАТНАШУЧЫЛАРНЫ КРЕМЛЬДӘ КАБУЛ ИТҮ

2 нче февральдә „Седов“ бозваткычының героик хәрәкәтендә катнашучыларны кабул итү үткәрелде. Кабул итү ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы тарафыннан оештырылды.

18 сәгаткә Кремльнең Зур Сараенда кабул итүгә чакырылган кунаклар—ВКП(б) Үзәк Комитеты членнары, СССР Верховный Советы һәм РСФСР Верховный Советы депутатлары, Халык Комиссарлары, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты югары командованиесенең вәкилләре, седовчыларның семья членнары, „И. Сталин“ бозваткычында экспедициядә катнашучылар, фәннең, техниканың, әдәбиятның, сәнгатнең күренекле эшлеклеләре, Москва предприятиеләренең стахановчылары җыелдылар.

Георгиевский зал шыгырым тулы. Залда җыелучылар седовчыларның—котып стихиясен батыр рәвештә буйсындыручыларның совет халкындагы иң яхшы сыйфатларны гәүдәләндерүчеләрнең, совет халкының батырлыгын, геройлыгын, җиңүгә карата чиксез ихтиарын, үзләренең бөек Ватаннарына чиксез мәхәббәтне, Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән чиксез бирелгәнлекне гәүдәләндерүчеләрнең — залда күренүен гаять зур күтәренкелек, көчле алкышлар һәм котлау тавышлары белән каршыладылар.

18 сәгат. Залга И. В. Сталин, В. М. Молотов, К. Е. Ворошилов, Л. М. Каганович, М. И. Калинин, А. А. Андреев, А. И. Микоян, Л. П. Берия, Н. М. Шверник, Г. М. Маленков, Н. А. Булганин, М. Ф. Шкирятов иптәшләр килеп керәләр. Җыелучылар иптәш Сталинны һәм аның көрәштәшләрен шатлык белән котлыйлар. Седовчылар бер-бер артлы иптәш Сталин янына киләләр. Ул аларның кулларын дусларча бик нык кыса. Партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре седовчылар белән җылы рәвештә исәнләшәләр. Алкышлар берничә минут дәвам итә.

Залда тантана һәм бәйрәм күренеше. Кунаклар арасында Вышинский, Бадаев, Буденный, Кузнецов, Кулик, Локтионов, Шапошников, Щербаков, Ярославский, Малышев, Лихачев, Тевосян, Бенедиктов, Ванников, Ульрих, Хмельницкий, Михайлов, Кафтанов, Храпченко, Николаева иптәшләр, Советлар Союзы Геройларыннан Громов, Коккинаки, Ширшов, Данилин, Шмидт, Кренкель, Федоров, Алексеев, Гризодубова, Раскова, Водопьянов, Левченко, Ляпидевский. Доронин иптәшләр һәм башкалар бар.

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш **В. М. Молотов** котлау рече белән чыкты. Иптәш **Молотов** болай ди:

— Иптәшләр! Хәзер безнең арабызда Арктиканың унбиш герое, бөек Ватаныбызның даны өчен, бөек Ленин—Сталин партиясенең даны өчен тиңдәше булмаган батырлык эшләгән унбиш герой—илебезнең унбиш герое бар.

Бадигин, Трофимов, Ефремов, Буйницкий, Полянский, Соболевский, Буторин, Токарев, Алферов, Бекасов, Шарыпов, Недзвецкий, Гетман, Гаманков, Мегер иптәшләрне героик хәрәкәтнең тәмам булуы белән котларга, „Иосиф Сталин“ бозваткычы экипажын экспедиция начальнигы Советлар Союзы Герое иптәш Папанин җитәкчелегендә җаваплы рейсны гүзәл рәвештә тәмам итүе белән котларга рөхсәт итегез.

Иптәш Молотов көчле кул чабулар астында советның унбиш батыры—данлыклы седовчылар хөрмәтенә бокал күтәрә.

Аннары кабул итүдә катнашучылар, үзенә тапшырылган эшне намус белән үтәгән „Иосиф Сталин“ бозваткычы командасы өчен, „Седов“ бозваткычын бозлар арасыннан чыгару экспедициясенең начальнигы иптәш Папанин өчен иптәш Молотовның тәкдим итүе буенча бокал күтәрәләр.

Большевикларның бөек партиясе турында иптәш Молотовның сүзләре гаять зур күтәренкелек тудыра. Бу партиянең байрагы астында күп санда җиңүләргә ирешелде, яңадан-яңа хәл иткеч җиңүләргә ирешелә һәм киләчәктә дә ирешеләчәк.

— Иптәш Сталинның сәламәтлеге өчен, бөек партиябез өчен!—ди иптәш Молотов. Кабул итүдә катнашучылар урыннарыннан торып алкышлар ясыйлар, иптәш Сталин хөрмәтенә, Ленин—Сталин партиясе хөрмәтенә бик күп котлау тавышлары яңгырый.

Иптәш Молотов иптәш К. С. Бадигинга сүз бирә. Кабул итүдә катнашучылар „Седов“ бозваткычының данлыклы капитанын кайнар рәвештә котлыйлар.

Иптәш Бадигин болай ди:

— Иптәшләр, хәрәкәтнең бөтен вакты эчендә безгә һәр көн игтибар күрсәткән өчен, безнең үзебез турында гына түгел, бәлки семьяләребез турында да чиктән тыш зур кайгыртучанлык күрсәткән өчен, седовчы унбиш моряк исменнән бөек коммунистлар партиясенә, Совет хөкүмәтенә, безнең сөекле һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез.

Бу ярдәм һәм игтибар, безнең юлыбызда очраган барлык кыенлыкларны җиңәргә ярдәм иттеләр. Партия һәм хөкүмәтнең игтибары, иптәш Сталинның аталарча кайгыртучанлык күрсәтүе безнең көчләребезне ун тапкыр арттырдылар, безне җиңелмәслек иттеләр.

Мин безнең Сталин өчен бокал күтәрәм! Ура, иптәшләр! Залда көчле алкышлар бик озак яңгырый. Иптәш Сталин хөрмәтенә һәр яктан көчле „ура“ тавышлары ишетелә.

Аннары „Седов“ бозваткычының политик эшләр буенча капитан ярдәмчесе иптәш **Д. Г. Трофимов** чыга. Аны көчле кул чабулар белән каршылыйлар. Иптәш Д. Г. Трофимов, җылы рәвештә кабул иткән өчен партия һәм хөкүмәт җитәкчеләренә тирән дулкынлану хисе белән рәхмәт белдерә. Ул, седовчыларның—Советлар Союзының гади гражданнарының — партия һәм хөкүмәт заданиесен намус белән үтәргә, үзләренең кулыннан килгән бөтен нәрсәне эшләргә тырышканлыклары турында сөйли. Иптәш Трофимов дәвам итеп:

— Безнең илебездә, социализм илендә бөтен халык бөек Ленин—Сталин партиясе тирәсенә бик нык тупланган. Седовчылар теләсә нинди яңа заданиене шатлык белән үтәргә хәзер торалар,—ди.

Иптәш Трофимов Совет хөкүмәтенең башлыгы Вячеслав Михайлович Молотовның сәламәтлеге өчен бокал күтәрә.

Яңадан алкышлар яңгырый.

Кабул итүдә катнашучылар „Иосиф Сталин“ бозваткычындагы экспедиция начальнигы Советлар Союзы Герое иптәш **И. Д. Папаниның** чыгышын кайнар рәвештә каршылыйлар. Ул болай ди:

— Кадерле иптәшләр! Үзебезнең Совет хөкүмәтенең, сөеклебез иптәш Сталинның тапшырган эшен, заданиесен үтәүне хис итүдән дә зуррак бәхет юк. Электә дә, капитализм вактында да „Ермак“, „Литке“ бозваткычлары бар иде, ләкин алар еракка йөзү өчен бик сирәк китәләр иде. Ә безнең илебездә әкияттәге кебек бик гаҗәп эшләр эшләнә. Әгәр дә элек кемгә булса да, бозваткыч котып төнендә Арктиканың югары киңлекләренә китә дип әйтсән, без: „акылдан язган кешеләр! Үлекләрне күмү өчен ак күлмәкләр тегегез“ дигән җавапны ишеткән булыр идек. Ләкин безнең илебездә кыш көне Арктикага поход мөмкин булды. Без бөек Сталин исме белән кыю рәвештә Гренландия диңгезе бозларына юнәлдек. Шушы исем белән безнең котыпчыларыбыз кыен шартларда эшлиләр. Сталинның исме, аның кайгыртучанлык күрсәтүе безне кыенлыклар турында да, котып төне турында да, Арктика бозларының үлү куркынычлары турында да онытырга мәҗбүр итә.

Безнең котыпчылар армиясе һичбер төрле кыенлыклардан курыкмый һәм безнең Сталинның беренче чакыруы белән үк теләсә нинди батырлыкларга барырга хәзер тора. Әгәр дә партия һәм хөкүмәт кушсалар, без үзебезнең сөекле—Эшче - Крестьян Кызыл Армиясе белән ак финнәрне, фин халкының палачларын бетерү өчен барырбыз.

Иптәш Папанин үзенең речен тәмам итеп:

— Безнең халкыбызның гомуми сөеклесе өчен!—ди.

Иптәш Ворошилов хөрмәтенә, җиңелмәслек - Эшче - Крестьян Кызыл Армиясе хөрмәтенә көчле „ура!“ һәм котлау тавышлары яңгырый.

Иптәш Молотов иптәш М. И. Калинин хөрмәтенә бокал күтәрә. Кабул итүдә катнашучылар СССР Верховный Советы Президиумы Председателен кайнар рәвештә кул чабулар белән котлыйлар.

Кабул итү дуслык обстановкасында берничә сәгат дәвам итте. Кабул итүдә катнашучылар өчен СССР Совнаркомы янындагы Сәнгат Эшләре Комитеты тарафыннан оештырылган зур концерт бирелде.

(ТАСС).

БЕЛОРУССИЯ ВОКЗАЛЫ МӘЙДАНЫНДА МИТИНГ

Иптәш Н. А. Булганин рече

(ССР Союзы Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты исменнән)

Иптәшләр! Союз Халык Комиссарлары Советы һәм Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе Үзәк Комитеты миңа Бадигин һәм Трофимов иптәшләргә һәм Төньяк Боз Океанында героик хәрәкәтнең кыенлыкларын уңышлы төстә җиңгән „Седов“ның бөтен данлыклы экипажына чын күңелдән сәлам тапшыруны йөкләделәр.

Рәхимсез Арктика стихиясен куркусыз һәм уңышлы рәвештә җиңгән „Георгий Седов“ бозваткычының бу героик хәрәкәтен, данлыклы 15 котып морягының эшен совет халкы 2 елдан артык вакыт буена зур игтибар белән күзәтеп торды.

Седовчыларның сугышчан рухын нәрсә күтәрде һәм аларга рәхимсез Арктиканы җиңәргә нәрсә ярдәм итте?

Бу сорауга седовчылар үзләре бик яхшы җавап бирделәр.

Иптәш Сталин исменә язган рапортларында седовчылар үзләрен барлык кыенлыкларны җиңүгә Ватаныбыз, Советлар Союзы, большевиклар партиясе һәм иптәш Сталин рухландырды дип яздылар.

Шушы шартларда үзләренең 812 көнгә сузылган хәрәкәтләре вактында седовчылар барлык кыенлыкларны җиңделәр һәм Ватаныбызга җиңүчеләр булып кайталар.

Котып бассейнының рәхимсез бозлары арасында седовчылар гаять зур фәнни эш алып бардылар. Седовчылар Арктика турындагы белемне киңәйттеләр. Бу, Төньяк диңгез юлын нормаль төстә эшләүче транспорт магистрале итеп әверелдерү бурычын үтәргә нык ярдәм итәр. Совет халкы алдында седовчыларның гаять зур хезмәте әнә шунда.

Седовчылар үзләренең үрнәкләре белән совет халкының большевистик омтылыш, батырлык һәм оешканлык ныклыгын күрсәттеләр.

Соңгы вакытта без үзебезнең данлыклы морякларыбыздан торган икенче бер коллектив тарафыннан эшләнгән гүзәл эшнең дә шаһите булдык.

„Седов“ны Арктика бозларыннан чыгарырга мөмкин булгач та хөкүмәт седовчыларны алырга „Иосиф Сталин“ бозваткычын җибәрде. Бу бозваткычның командасы үзенә йөкләнгән заданиене намус белән үтәде.

Хөкүмәт „Седов“ бозваткычын Гренландия диңгезе бозларыннан чыгару заданиесен бик яхшы үтәгән „Иосиф Сталин“ бозваткычының батыр командасына рәхмәт белдерә.

Халык Комиссарлары Советы һәм партиянең Үзәк Комитеты исменнән мин иптәш Папанинны, шулай ук бозваткычның капитаны иптәш Белоусовны һәм бозваткычның бөтен гүзәл экипажын котлыйм.

„Иосиф Сталин“ бозваткычы экипажы үзенең үрнәге белән үз хөкүмәтенең заданиесен совет кешеләренең тиз, үз-үзләрен аямыйча оешкан рәвештә үти белүләрен күрсәтте.

Яшәсен героик седовчылар һәм „Иосиф Сталин“ бозваткычы командасы!

Яшәсен батыр совет халкы һәм аның большевистик омтылышы, батырлыгы, оешканлыгы һәм үзенең намусы өчен, үзенең Ватаны өчен, үзенең бөек Ленин—Сталин партиясе өчен көрәшә белүе! **(Озакка сузылган көчле кул чабулар. Оркестр „Интернационал“ уйный).**

Иптәш К. С. Бадигин рече

Кадерле иптәшләр! „Седов“ моряклары миңа сезне, туганыбыз Москва хезмәт ияләрен чын күңелдән, бөтен йөрәгебездән котлауны тапшырдылар. Котып төнендә һәм салкында, Арктика бозлары арасында без һәр вакыт үзебезнең Ватан белән өзлексез элемтәбезне хис иттек. Безнең алдыбызда һәр вакыт сөекле Москва торды, Котып төне аркылы без Кремль йолдызларын күрдек. Хәрәкәтебезнең иң авыр минутларында без Ватаныбызның җылы сулышын хис иттек. Ул безне бураннарда һәм салкыннарда җылытты, безгә мәкерле стихиянең кыенлыкларын һәм киртәләрен җиңүдә яңа көчләр бирде. Без кайда гына булсак та совет халкының куәтле кулын, аның ышанычлы ярдәмен, аның кайгыртучанлыгын һәм игтибарын хис иттек.

Безнең кечкенә коллективыбыз үзен бөек совет халкының вәкиле дип санады һәм без Ватан каршындагы, партия каршындагы, иптәш Сталин каршындагы бурычыбызны үтәү өчен совет кешеләренә лаеклы булганча: тыныч, ышаныч белән һәм ныклык белән эшләргә тырыштык. Бу ышанычны һәм тынычлыкны без совет халкына карата мәхәббәттән, партиянең һәм хөкүмәтнең ярдәменнән һәм игтибарыннан алдык. Безнең большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты һәм Совет хөкүмәте, иптәш Сталин һәм иптәш Молотов үзләре седовчыларны үзләренең игтибарлары һәм кайгыртучанлыклары белән чолгап алдылар. Без иптәш Сталинчан һәм иптәш Молотовтан өч тапкыр котлау алдык. Бу—гаять зур бәхет. Безнең өчен, совет кешеләре өчен иптәш Сталин сәламеннән дә, иптәш Сталинның безнең эшне яхшы дип табуыннан да кадерлерәк нәрсә юк! Шулай булгач, иптәшләр, чиксез, мең ел яшәргә телисең һәм шушы бөтен мең еллык гомереңне үзеңнең Ватаныңа, үзеңнең халкыңа бирергә телисең.

Хәрәкәтебезнең уңышы өчен, аның барлык нәтиҗәләре өчен без иптәш Сталинга бурычлы. Бозлар арасында яшәүнең иң кыен моментларында да иптәш Сталин исме безнең уебыздан чыкмады. Лаптевлар диңгезеннән Гренландия бозларына кадәр булган юлны без иптәш Сталин исме белән үттек. Бу исем безгә Котып төне караңгылыгында яктылык биреп торды. Сталин булган урында—караңгылык юк, анда шатлык, анда яктылык, анда тормыш.

Иптәшләр, билгеле безнең авыр сәгатләребез дә булды. Ләкин без куркыныч нинди генә зур булса да, безгә ярдәмгә Ватаныбыз киләчәкне, иптәш Сталин киләчәкне белдек. Безнең төньякка хәрәкәт итүебезнең куркынычлы моменты килеп җиткәч, хөкүмәт карары буенча Гренландия диңгезе бозларына юлбашчыбыз исемендәге бозваткыч җибәрелде.

Менә шушы шартларда экспедиция халык герое Папанин җитәкчелегендә „Седов“ янына килеп җитте һәм безне бозокеаныннан коткарды.

Хөкүмәтебезгә, партиябезгә, иптәш Сталинга үзебезнең чын күңелдән рәхмәт хисләребезне ничек белдерик!

Туган Совет җиренә аяк басканда седовчылар үзләренең бөтен көчләрен, бөтен белемнәрен, бөтен тормышларын һәм эшләрен Ватаныбыз файдасына, совет халкы файдасына, Ленин—Сталин партиясе эшенә багышларга ант иттеләр.

Без, иптәшләр, рядовой совет кешеләре. Безнең кебекләр миллионнарча. Безнең куәтебез әнә шунда, горурлыгыбыз әнә шунда, көчебез әнә шунда. совет халкының бердәмлеген, Советлар Союзының куәтен, социалистик стройның ныклыгын бер нәрсә дә җимерә алмас. Совет халкы җиңелмәслек. Советлар иле җиңелмәслек! Гүзәл Ватаныбыз чәчәк атсын һәм үссен!

Яшәсен безнең данлыклы һәм җиңүчән Ленин—Сталин партиясе!

Яшәсен безнең Совет хөкүмәте һәм аның башлыгы иптәш Молотов!

Яшәсен социализм җиңүләрен оештыручы, атабыз һәм дустыбыз иптәш Сталин! **(Озакка сузылган көчле кул чабулар, „Интернационал“).**

Иптәш А. С. Щербаков рече

(Москва шәһәренең хезмәт ияләре исменнән)

Иптәшләр! Партиянең Москва Комитеты, хезмәт ияләре депутатларының Москва Советы Башкарма Комитеты исменнән, башкаланың большевиклары һәм барлык хезмәт ияләре исменнән туган башкалабыз Москвага кайткан герой седовчыларга чын күңелдән сәлам тапшырам!

Сез, седовчы иптәшләр, гаять кыен шартларда фәнни тикшерү эшләре алып бардыгыз. Бу эш—бөтен дөнья фәненә кыйммәтле хәзинә. Сез—большевиклар партиясе тарафыннан тәрбияләнгән кешеләр—совет кешеләренең баһадирлык көче, омтылышы һәм батырлыгы нәрсәдән гыйбарәт икәнлекне бөтен дөньяга тагын бер кат күрсәттегез. Совет халкы дөньядагы иң алдынгы фәннең—Совет фәненең тагын бер җиңүе белән горурлана ала. Менә шуңа күрә дә бөтен илебез сезне, үзенең сөекле улларын геройлар сыйфатында каршы ала.

Партия һәм Совет хөкүмәте заданиесен бик яхшы үтәгән „Седов“ бозваткычының батыр экипажына һәм аның капитаны иптәш Бадигинга дан һәм хөрмәт.

Иптәшләр! Совет халкы максатка ирешү юлындагы барлык киртәләрне җимерүче кыю һәм батыр кешеләрне, бер кайчан да ярты юлда туктап калмыйча, һәр вакыт алга һәм алга гына баручы кешеләрне ярата.

Үзләренең Ватаннарына чын күңелдән бирелгән мондый кешеләрне безнең большевиклар партиясе һәм иптәш Сталин тәрбияләп үстерә. Стихиягә каршы көрәштә бөтен дөньяга яңа батырлык үрнәге, ныклык, тотанаклылык һәм большевистик тырышлык үрнәге күрсәткән седовчылар нак әнә шундый кешеләр.

Капиталистик илләрдә дә талантлы һәм сәләтле кешеләр аз түгел. Ләкин анда фән өчен, Арктиканы үзләштерү өчен шулай үз-үзләрен аямыйча көрәшүче геройлар ни өчен табылмый соң? Чөнки анда бөтен эш табышка, файдага, акчага буйсындырылган, ә хезмәт ияләре арасыннан чыгучы талантларга юл ябык.

Патша Россиясендә дә халык талантларына һәм кыю кешеләргә юл шундый ук ныклы стена белән ябык иде. Аларның иң яхшылары, ялгыз геройлар еш кына үзләренең тормышларын корбан иттеләр. Безнең Совет бозваткычына үзенең исме бирелгән Георгий Седов моның мисалы.

Мондый батырлыклар бары тик Советлар илендә генә мөмкин булды, үзләренең Ватаннары хакына бары тик совет кешеләре генә батырлык эшләргә сәләтле. Ватанга мәхәббәт, аның куәтенә ышану—совет кешеләрен рухландыручы көч әнә шул.

„Седов“ бозваткычының экипажы элек тын гына яшәгән боз сәхрасына юл салды. Бөтен совет халкының, партиябезнең, хөкүмәтебезнең һәм иптәш Сталинның фикерләре һәм хисләре сезнең белән, иптәшләр, 15 кыю моряк белән бергә булды.

Арктикада эшләү шартлары гаять куркынычлы. Анда табигать кешеләрне шундый кыенлыклар алдына куя ки, омтылыш, ныклык һәм батырлык иң ныклы сыналудан үтәргә тиеш була. Ләкин сез, иптәшләр, нык булдыгыз, сез илнең үзегезгә һәрбер минутта ярдәмгә киләчәген белдегез.

Анда, бозлы ерак Арктикада Ватаныбыз, бөтен совет халкы сезнең белән булды.

Сезне боз тоткынлыгыннан тартып алу өчен Совет флотының данлыклы карабы „Иосиф Сталин“ җибәрелде. Аның бортында Советлар Союзы герое, сыналган котыпчы иптәш Папанин җитәкчелегендәге батыр совет кешеләре булды.

Советлар иле—геройлар Ватаны. Большевиклар партиясе, иптәш Сталин һәрбер совет кешесендә социалистик Ватан өчен һәм аның куәтен ныгыту өчен батырлыкларга омтылу тәрбиялиләр.

Безнең данлыклы очучыларыбыз, танкистларыбыз, Кызыл Армиянең сугышчылары, командирлары һәм политработниклары аның көчен көнчыгышта һәм көнбатышта ныгыттылар, ә хәзер Финляндия хезмәт ияләренә ярдәм итәләр, Ленин шәһәренең оборонасын, димәк бөтен илебезнең оборонасын тәэмин итәләр. Башкала хезмәт ияләре намуслы рәвештә эшләп, үзләренең бөтен көчләрен шул ук бурычны хәл итүгә бирәләр. Сез Арктиканың рәхимсез киңлекләрендә Советлар иленең данын арттырдыгыз.

Совет кешеләренең менә шушы омтылыш һәм туплану бердәмлегендә, Ленин—Сталин партиясенә аларның чын күңелдән бирелгәнлегендә большевиклар ала алмаган крепостлар юк дигән гади һәм шул ук вакытта бөек чынбарлык раслана.

Иптәшләр, сез партиянең һәм халыкның ышанычын акладыгыз, ә бу—совет кешеләренең тормышында хәл иткеч нәрсә. Седовчылар батырлыгының—Совет котыпчыларының 812 көн хәрәкәт итүенең тәрбия ягыннан гаять зур әһәмияте бар. Сезнең гүзәл җиңүегез, сезнең героик хәрәкәтегез һәрбер совет кешесендә үзенең дәүләте файдасына тагын да тырышыбрак эшләргә, бөек Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә тагын да күбрәк энергия һәм ныклык белән эшләргә теләк тудыра.

Яшәсен „Седов“ бозваткычының героик экипажы!

Яшәсен „И. Сталин“ бозваткычының экипажы!

Яшәсен безнең куәтле совет халкы!

Яшәсен остазыбыз һәм дустыбыз иптәш **Сталин!**

(Озакка сузылган көчле кул чабулар. Оркестр „Интернационал“ уйный).

Советлар Союзы герое иптәш И. Д. Папанин рече

Кадерле иптәшләр! Сөекле Ватаныбызның башкаласына, үзебезнең бөек Советлар Союзының йөрәгенә—туганыбыз Москвага без тирән тәэсирләнү һәм шатлану хисе белән кердек.

Без, котыпчылар, сезгә, Москваның эшчеләренә, хезмәткәрләренә, интеллигенциясенә, Кызыл Армиябезнең һәм Хәрби Диңгез Флотыбызның командирларына, сугышчыларына һәм политработникларына чын күңелдән үзебезнең ялкынлы большевистик сәламебезне тапшырабыз.

Без „Седов“ны боз тоткынлыгыннан азат итү турында большевиклар партиясе Үзәк Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советының мактаулы заданиесенен үтәлгәнлеген белдерүебез белән бәхетлебез. Ватаныбызның теләген тормышка ашырып, без данлыклы карабны Мурманскига алып килдек, Советлар Ватанының 15 патриотын, большевиклар партиясенең һәм халыкның турылыклы 15 улын Зур Җиргә алып кайттык.

Ленин—Сталин партиясе тәрбияләп үстергән совет кешеләре могҗизалар күрсәтәләр, бөтен дөньяны сокландырырлык кыюлык һәм батырлык күрсәтәләр. Алар теләсә нинди кыенлыкларны җиңүдә алга таба баралар һәм үзләренең юлларында һичбер төрле киртәләрне белмиләр. Аларга үзләренең Ватаннарына мәхәббәт, партиябезгә һәм бөек юлбашчыбыз, остазыбыз һәм дустыбыз иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгәнлек ярдәм итә.

Безнең илдә геройлык һәр җирдә дә күрсәтелә. Безнең социализм төзегән совет халкы бөтенесе—героик халык. Социализм илендә, кешеләре сугышчан большевиклар партиясе тарафыннан, җиңелүләрне белми торган партия тарафыннан тәрбияләнгән илдә башкача булырга да мөмкин дә түгел. Бары тик безнең ирекле илдә генә халыкта тулысынча батырлык һәм кыюлык тәрбияләнә. Үзенең сөекле Ватаны өчен, илебез алга, коммунизмга таба гаять зур адымнар белән барсын өчен тырышып эшләүне һәрбер совет гражданины үзенең изге бурычы дип саный.

Безгә, котыпчыларга партиянең һәм хөкүмәтнең җаваплы заданиесен үтәү бәхте туры килгәнлек белән без горурланабыз. Партиянең Үзәк Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы, иптәш Сталин һәм иптәш Молотов безне, котыпчыларны даими кайгыртучанлык һәм игтибар белән чолгап алалар. Партия җитәкчелегендә Арктиканы үзләштерү эшендә без зур уңышларга ирештек.

Без елдан-ел төньякка тирәнрәк үтеп керә барабыз. Совет котыпчылары үзләренең сөекле Ватаннары өчен, төньякның бөтен байлыкларын социализимга хезмәт итүгә кую өчен көчләрен кызганмыйча эшлиләр. Седовчы геройлар бу эшкә кыйммәтле хәзинә керттеләр. Алар Арктикада гаять кыйммәтле материал җыйнадылар. Бу материал Совет фәнен һәм бөтен дөнья фәнен баетыр. Прогрессив кешелек дөньясы совет галимнәреннән гаять зур фәнни бүләк алыр.

Седовчылар йөрәкләрендә Сталин исме булган хәлдә эшләделәр. Сталин исме безне, совет кешеләрен сугышчан батырлыкларга рухландыра. Бу исем белән халкыбыз бер-бер артлы данлыклы җиңүләргә ирешә. Иптәш Сталин җитәкчелегендә без дөньяда иң яхшы дәүләт төзедек. Бөек Сталин җитәкчелегендә җиңелмәслек, сөекле Кызыл Армия һәм куәтле Хәрби Диңгез Флоты төзелде. Большевиклар партиясе җитәкчелегендәге армиябез һәм флотыбыз җиңелмәслек. Читләр байлыгын яратучылар барсы да Совет коралының көчен үз җилкәләрендә татып карадылар. Без үзебезнең социалистик Ватаныбызны яратабыз һәм үзебезнең совет бәхтен, шатлыгыбызны, ирекле илдә чәчәк атучы тормышыбызны бер кемгә дә һәм бер кайчан да бирмәбез.

Совет халкы үз хөкүмәте тирәсенә, үзенең данлыклы большевиклар партиясе тирәсенә нык тупланган. Советлар Союзына кул күтәргән һәрбер дошман сытып ташланачак, тар-мар ителәчәк һәм юк ителәчәк.

Яшәсен Ватаныбыз һәм бөек совет халкы!

Яшәсен сөеклебез һәм бер кем дә җиңә алмаслык Кызыл Армиябез һәм Хәрби Диңгез Флотыбыз!

Яшәсен безнең зирәк Совет Хөкүмәте һәм аның башлыгы иптәш Молотов!

Яшәсен юлбашчыбыз һәм остазыбыз, кешелек дөньясының даһие, туганыбыз иптәш **Сталин!** Ура, иптәшләр! **(Кул чабулар. „Ура!“ тавышлары, „Интернационал“).**

ТАССР ның XX еллыгына хәзерлек

Данлыклы юбилейне зур җиңүләр белән каршыларбыз

Казшвейпром артеле членнарының 3 нче февральдә булган җыелышында Татарстан республикасының данлыклы XX еллык юбилеен производствода яңа җиңүләр белән каршылау турында Казан Мехкомбинаты эшчеләре һәм инженер-техник работникларының мөраҗәгате тикшерелде. Җыелыш зур күтәренкелек һәм активлык белән үтте.

Җыелышта катнашучы иптәшләр үзләренең чыгышларында предприятиеләрдә юбилей көннәренә хәзерлек эшләрен башлап җибәрү өчен бу мөраҗәгатнең бик вакытлы һәм әһәмиятле булуын әйттеләр.

Артельнең атаклы стахановчысы—ике станокта эшләүче һәм актив җәмагат эшчесе иптәш Вәлиева үзенең чыгышында болай диде:

— Мин январь аенда ике станокка бирелгән норманы 380 процент итеп үтәп, 700 сумнан артык хезмәт хакы алдым. Норманы 2—3 тапкыр арттырып үтәүче стахановчыларны безнең артельдә күп табарга була. Ләкин әле бу чик түгел. Эш сәгатьләреннән тулысынча файдаланган вакытта бездә хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да югарырак күтәрергә мөмкин. Без стахановча эшләп, данлыклы юбилей көнен гүзәл казанышлар белән каршыларбыз. Мин юбилей хөрмәтенә көнлек планны 400 процент итеп үтәп барырга, ә бригадамда ярты еллык планны 25 нче июнь көненә 130 процент итеп үтәргә һәм бары тик яхшы сыйфатлы продукция эшләп чыгарырга йөкләмә алам.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды исемендәге яшьләр бригадасы җитәкчесе иптәш Полуялова тегүчеләр бригадасында ярты еллык планны 25 нче июнь көненә 140 процент итеп үтәү йөкләмәсен алды.

Җыелыш январь аенда төзелгән социалистик ярыш договорларының үтәлешен тикшерү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм ярты еллык планны яхшы сыйфат күрсәткечләре белән 25 нче июнь көненә арттырып үтәү турында карар кабул итте.

Ф. С.

Яңа йөкләмәләр алдылар

Кичә, индивидуаль заказлар буенча аяк киемнәре эшләү фабрикасы эшчеләренең, инженер-техник работникларының һәм хезмәткәрләренең гомуми җыелышы булды. Гаять зур бердәмлек һәм рөешканлык белән үткән бу җыелышта Казан мехкомбинаты коллективының мөраҗәгате тикшерелде. Хатын-кызлар өчен аяк киемнәре эшләү цехы стахановчысы иптәш Шпигин җыелышта болай диде:

— Тагын 5 айдан орденлы республикабызның барлык хезмәт ияләре данлыклы XX еллыкны бәйрәм итәчәкләр. Үткән вакыт эчендә Татарстан республикасы Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә танымаслык булып үзгәрде. Татарстанның промышленносте һәм авыл хуҗалыгы гигант адымнар белән үсте. Без бу данлыклы бәйрәмне истә калдыру өчен производствода тагын да яхшырак эшләрбез. Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерербез.

Аннан соң стахановчылардан Димитриев, Грибинский, Горлов һәм башка иптәшләр сөйләделәр. Алар мехчылар чакыруына бердәм рәвештә кушылганлыкларын белдерделәр. Фабрика коллективын мехчылар чакыруына конкрет эш белән җавап бирүгә чакырдылар.

Җыелышта катнашучылар, 1940 нчы елның беренче яртысы планын Татарстанның XX еллыгына тулысынча үтәргә, хатын-кызлар һәм ирләр өчен 12 төрле яңа фасон аяк киемнәре эшләп чыгарырга булдылар. Алар берничә профессияне үзләштерәчәкләрен, Татарстанның XX еллыгы көненә фабриканың тоташ стахановча эшләвенә ирешәчәген әйттеләр. Барлык цехларда ныклы хуҗалык исәбен булдыруны, фарнитураларга, электроэнергиягә экономия ясау өчен ныклы көрәш алып баруны ышандырдылар.

К. Х.

Берьюлы 30 аппаратта эшләү

С. М. Киров исемендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводында күп станокта эшләүчеләр саны көннән-көн арта бара.

7 нче номерлы цехның стахановчылары Ураинская, Большакова һәм Маркухина иптәшләр 12 аппаратта эшләү урнына бер юлы 24 аппаратта эшләп, бик яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр. Хәзер алар 30 аппаратка хезмәт күрсәтүгә күчтеләр. Аппаратчылардан Цивильский, Горожанина, Булданов һәм Соболева иптәшләр шулай ук бер юлы берничә аппаратка хезмәт күрсәтә башладылар.

Заводның уйлап табучылары хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү өчен көрәшәләр. 8 нче цехның уйлап табучыларыннан Гордеев, Фирсов һәм Кудрявцев иптәшләр каучук кисү өчен механик пычак хәзерләү өстендә эшлиләр. Цехның рационаллаштыручылары аппаратларга чимал тутыру һәм аларны бушату эшләренең механизациясен яхшырту өстендә эшлиләр.

Заводның күпчелек цехлары беренче квартал планын срогыннан алда үтәү өчен йөкләмә алдылар. 6 нчы номерлы цех коллективы еллык планны 110 процент итеп үтәү, материалларга саклык белән карау турында йөкләмә алды.

РӘСЕМДӘ: Медицина фәннәре өлкәсендә күренекле хезмәтләре өчен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы указы буенча дәрәҗәләр бирелгән Казан Дәүләт Медицина институты работникларыннан бер төркем. Сулдан уңга (беренче рәттә): „Татарстан АССР ның атказанган фән эшлеклесе“ дигән исем алучы профессорлардан И. П. Васильев, В. В. Милославский, Н. К. Горяев, Л. И. Омороков; икенче рәттә—Б. Л. Мазур, А. Г. Терегулов һәм Татарстан АССР ның почет грамотасы белән бүләкләнүче С. Фәйзуллин һәм А. П. Яковлева иптәшләр.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Татарстан АССР ның атказанган фән эшлеклесе исемен бирү турында

Медицина фәне өлкәсендә күренекле хезмәтләре өчен Татарстан АССР ның атказанган фән эшлеклесе исемен бирергә:

1. Иван Петрович **Васильевка**—Казан Дәүләт Медицина институтының Патологик анатомия кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы;

2. Валериан Владимирович **Милославскийга**—Казан Дәүләт Медицина институтының гомуми гигиена кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы;

3. Николай Константинович **Горяевка**—Казан Дәүләт Медицина институтының госпиталь терапия кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы;

4. Леонид Иванович **Омороковка**—Казан Дәүләт Медицина институтының нерв авырулары кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы;

5. Берк Литманович **Мазурга**—Казан Дәүләт Медицина институтының туберкулез кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы;

6. Әбүбәкер Гәрәй улы **Терегуловка**—Казан Дәүләт Медицина институтының эчке авырулар пропедефтика кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы;

7. Николай Владимирович **Соколовка**—Казан Дәүләт Медицина институтының хирургия кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан, Кремль.
1 февраль, 1940 ел.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасы белән бүләкләү турында

Эшкә үрнәк булырлык тестә намуслы караган өчен Казан Дәүләт Медицина институтының түбәндәге работникларын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының почет грамотасы белән бүләкләргә:

1. Кузьма Амфилохиевич **Дрягинны**—Казан Дәүләт Медицина институтының терапия кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы;

2. Рөстәм Галләм улы **Вяселевне**—Казан Дәүләт Медицина институтының хирургия кафедрасы ассистенты, медицина фәннәре кандидаты;

3. Мөхәммәт Габдулла улы **Ерзинны**—Казан Дәүләт Медицина институтының патологик физиология кафедрасы ассистенты, медицина фәннәре кандидаты;

4. Салих Гыйрфан улы **Файзуллинны**—Казан Дәүләт Медицина институтының биология кафедрасы ассистенты;

5. Хәбибулла Нурмөхәммәт улы **Әмиревне**—Казан Дәүләт Медицина институтының нормаль анатомия кафедрасы ассистенты;

6. Глафира Николаевна **Соколовны**—Казан Дәүләт Медицина институтының акушерлык-гинекология клиникасы фельдшерицасы;

7. Кирилл Осипович **Софиенконы**—Казан Дәүләт Медицина институтының физико-коллоид химия кафедрасы препараторы;

8. Александра Петровна **Яковлеваны**—Казан Дәүләт Медицина институтының терапевтик клиникасының санитаркасы;

9. Анастасия Тимофеевна **Орловны**—Казан Дәүләт Медицина институтының акушерлык-гинекология клиникасының санитаркасы;

10. Гыйлажеттин Гайнеттин улы **Вахитовны**—Казан Дәүләт Медицина институтының швейцаре.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан, Кремль.
1 февраль, 1940 ел.

Яңа җиңүләр өчен көрәшкә

Без бүген газетада Казан Дәүләт Медицина институты коллективының алдынгыларын—профессорларына, республикабызның атказанган фән эшлеклесе дигән исемне бирү һәм почет грамотасы белән бүләкләү турында Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының указын урнаштырабыз.

Моннан берничә көн элек, 28 нче январьда, орденлы Татарстанның хезмәт ияләре, совет медицина фәненең барлык эшлеклеләре медицина институтының гүзәл 125 еллыгын гаять зур шатлык белән бәйрәм иттеләр. Бу көннәрдә юбиляр исменә килгән котлау хатлары, телеграммалар аның үткән тарихи юлын һәм ирешкән уңышларын күрсәтеп, юбилярне тагын да яңа җиңүләр өчен, совет медицина фәненең тагын да алга атлавы өчен көрәшкә чакырдылар.

Казан Медицина институты зур тарихи юл үтте. Элек Казан Дәүләт университетының бер факультеты булган бу институт, Советлар власте елларында бөек большевиклар партиясе җитәкчелегендә илебезнең иң эре югары уку йортларыннан берсе булып, совет медицинасы кадрларын тәрбияләүче учак булып әверелде.

Институт, совет халкының сәламәтлеген саклау өчен армый-талмый көрәшүче йөзләрчә һәм меңнәрчә эшлеклеләрне, гүзәл белгечләрне тәрбияләде.

Совет медицина фәнен тагын да үстерүдә, аны оештыруда Казан Медицина институтының тоткан урны гаять зур. Экспериментал медицина Бөтенсоюз Институтының иң эре алты бүлегенең бишесенә Казан Медицина институтында тәрбияләнүчеләр җитәкчелек итәләр. Алар—Сперанский, Андреев, Быков, Вишневский, Разенков һәм Лаврентьев иптәшләр. Бу һәм хәзерге профессорлар, укытучылар составының югары квалификацияле булулары Казан институтын Советлар Союзында иң беренче урыннарның берсенә куя.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы совет халкының сәламәтлеген саклауда медицина институты ирешкән гаять зур уңышларны күрсәтеп, институтны һәм аның алдынгы кешеләрен бүләкләде.

Казан Медицина институтын һәм аның алдынгыларын бүләкләү институт алдына тагын да бөегрәк бурыч куя. Институт коллективы, Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, бу бөек ышанычны тулысынча аклар һәм Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның һәр вакыт җиңүчән таглиматы белән коралланган югары белемле кадрлар хәзерләп, алдынгы совет фәне байрагын тагын да югары күтәрер.

Финанс бурычларын уңышлы үтәргә

С. ШӘРӘФИЕВ

Татарстан АССР финанс халык комиссары, СССР Верховный Советы депутаты

Үткән елның йомгаклары халык хуҗалыгының барлык тармаклары буенча гүзәл үсеш барлыкны, халык массасының иҗад инициативасының тагын да нык үсүен, совет кешеләрендә бөек патриотизм хисләренең көчле үсүен күрсәтәләр.

Үткән елның йомгаклары зур. Ләкин 1940 нчы елгы бурычлар тагын да зуррак, барлык хезмәт ияләре аларны тормышка ашыру өчен тагын да ныграк энергия белән көрәшәләр.

1940 нчы елгы бурычлар финанс органнары һәм күп санлы финанс активы алдына бик зур һәм гаять җаваплы таләпләр куялар.

Ачыграк булсын өчен Татарстанда үткән елгы финанс эшенең йомгаклары турында кыскача туктталып үтик.

Мәгълүм ки, дәүләт доходлары, ачыграк әйткәндә,—оборот налогы безнең бюджетның төп һәм хәл иткеч чыганагы. Бу төп тармак буенча Татарстанда еллык план 100,9 процент итеп үтәлде.

Сәүдә оешмаларында булган җитешсезлекләрне төзеп торырга мөмкин булмаслык хурлыклы күренешләрнең берсе дип санарга кирәк. Урындагы 5 сәүдә оешмасы буенча гына да 1939 нчы елны 1 миллион 600 мең сумнан артык акча туздырылган.

Аннан соң идарә аппараты штатларын кирәгеннән артык киңәйтеп һәм ставкаларны законнан тыш арттырып, дәүләт исәбенә „юмартлык“ күрсәтү фактлары да булды.

Мәсәлән, Совхозтрестта (управляющие иптәш Зыбин) 1939 нчы елны 85 хезмәт буенча ставкаларны үз белдекләре белән арттыру аркасында 50 мең сум акча артык түләнгән.

Безнең ревизорларыбыз үзләренә куелган таләпләргә һәр вакытта да җавап биреп бетерә алмыйлар әле. Кай вакытларда ревизия кимчелекләрне һәм бозуларны күрсәтеп кенә үтә, ләкин аларны кичекмәстән бетерү өчен тиешле чараларны күрми.

Без ревизияләрнең формаль төстә булмыйча, чын ревизия булуларына ирешергә тиешбез. Ревизия, ачылган бөтен кимчелекләрне бетерүне тәэмин итәргә һәм эштәге барлык уңышлы якларны ныгытуга ярдәм итәргә тиеш.

Халыктан налог һәм страховой түләүләрен җыю буенча үткән елны бер кадәр яхшыру булды. Налог түләүләре планы 102,3 процент, страховой түләүләре 106 процент, шул исәптән иректе страхование түләүләре 139,6 процент итеп үтәлде.

Ләкин бу эштә дә әле безнең мөмкинлекләр тулысынча файдаланылмады. Планны системалы рәвештә үтәүче һәм арттырып үтәүче районнар белән бер рәттән, бездә әле начар эшләүче байтак кына районнар бар. Мәсәлән, Куйбышев (райфо мөдире иптәш Пырков), Тельман (райфо мөдире иптәш Садретдинов), Алабуга (райфо мөдире иптәш Бурмистров) һәм башка районнар.

Планны үтәмәгән район финанс бүлекләренең планны үтәмәүләренә бер нинди дә сәбәпләре юк. Бу бары тик аларның начар эшләүләреннән, финанс активистлары массасы белән элемтәдә булмауларыннан, массовый аңлату эшенең җитәрлек булмавыннан гына килә.

Налог эшендә түләү дисциплинасын бозучыларга, аерым алганда, ялгыз хуҗалыкчыларга карата яшәп килгән либерализм әле һаман да бетерелмәгән.

Мәсәлән, Шөгер районында ялгыз хуҗалыкчы Бари Гыйлаҗов ат белән эшләп, шактый зур доход ала. Ә район финанс бүлеге бу кешенең 900 сумнан артыграк акчаны түләмәвенә түзеп килгән.

Столбище район финанс бүлеге судның ялгыз хуҗалыкчылардан культура җыемнарын һәм башкаларны түләтү турындагы карарын 5 айдан бирле хәрәкәтсез яткырган.

Үткән елны авыл хуҗалыгы налогын СССР Верховный Советының чираттан тыш IV нче Сессиясе кабул иткән закон буенча салу налог эшендә гаять әһәмиятле урын тотты. Бу закон колхозчылар массасының үзләреннән тиешле сумаларны түләүдә активлыкларын шактый күтәрде.

1940 нчы елны финанс органнары налог һәм страхование түләүләре буенча аерым районнарда гына түгел, бәлки бөтен республика буенча эшнең бик яхшы баруын тәэмин итәргә тиешләр.

Налог законнарын дөрес итеп тормышка ашырырга, бер генә сум да түләнми калуга юл куймаска, массовый эшкә тиешле бәя биреп җиткермәүне кискен рәвештә бетерергә һәм, алдынгы районнардан үрнәк алып, күп санлы финанс активын эшкә тартырга, финанс активистлары арасында социалистик ярышны чынчынлап җәелдерергә кирәк.

Дәүләт заемнарын һәм саклык кассаларына акча салу эшен алга җибәрү өчен бездә киң мөмкинлекләр бар. Өченче Бишьеллык заемы (2 нче ел чыгарылышы) аннан элекке заемга караганда 16 миллион 334 мең сумлык артыграк таратылды. Саклык кассаларына салынган акчаның сумасы бер ел эчендә 5 миллион 500 мең сумнан артты. Татарстанның саклык кассаларында калган акчалар 48 миллион сумга җитә. 200 меңнән артык хезмәт иясе үзләренең акчаларын саклык кассаларында саклыйлар.

Ләкин шулай да бездә булган мөмкинлекләрнең уннан бер өлеше дә файдаланылмаган әле. Монда барыннан да элек саклык кассалары системасында эшләүче работниклар гаепле.

Саклык кассалары работниклары арасында бик яхшы эш үрнәге күрсәтүче, ел әйләнәсендә кассага акча салуны 2—3 тапкыр һәм аннан да күбрәк арттырган кешеләр бар.

Ләкин район саклык кассаларының җитәкчеләре һәм идарәләре алдынгыларның бу яхшы эш методларын күрмиләр.

Хезмәт ияләренең акча салулары елдан-ел арта бара. Совет кешеләренең саклык кассаларына салу өчен акчалары җитәрлек. Тик акчаларны саклык кассаларында саклауның уңайлы һәм файдалы икәнлеген яхшылап аңлатырга гына кирәк. Шул вакытта безнең саклык кассаларына акча салу эше тагын да көчлерәк барачак.

Партия һәм хөкүмәт финанс эшенә гаять зур әһәмият бирәләр. Ләкин кайбер урыннарда партия һәм совет оешмалары бу мәсьәләгә тиешенчә игтибар бирмиләр әле, финанс органнарының һәм саклык кассаларының эшенә тиешле контроль ясамыйлар, аларга бик начар җитәкчелек итәләр.

Мәсәлән, Дөбъяз районы үз бюджетын доходлар буенча 79 процентка гына үтәгән, бу—анда түләүләрне җыю планын начар үтәүдән килә. Заем буенча бюджетта билгеләнгәннең бары 63 проценты гына үтәлгән. Авылда заемга язылучылардан җыеп алынган акчаларның 90 проценты авыл советлары бюджетына китүен онытырга ярамый. Хәтта район башкарма комитетының, финанс мәсьәләләре белән бик начар шөгыльләнеп, район финанс бүлеген бюджет дисциплинасын бозуга үзе этәрү кебек фактлар да очрый. Мәсәлән, Бондюг район башкарма комитеты буенча бөтен ел өчен идарә расходларына билгеләнгән барлык акчалар ноябрьгә кадәр үк тотылып беткәннәр. Ләкин район башкарма комитеты тагын берничә мең сум акчаны үз исәбенә күчерүгә район финанс бүлеген мәҗбүр итә торган карар чыгаруны мөмкин дип тапкан. Ә район финанс бүлеге мөдире иптәш Васильев бу законсыз карарга протест белдермәгән һәм расходның артык тотылуына юл куйган.

1940 нчы елгы бурычлар финанс эшенә партия һәм совет оешмаларының, бөтен совет җәмәгатчелегенең игтибарын кискен рәвештә көчәйтүне таләп итәләр.

Финанс эшен ничек яхшырак оештырырга, планнарны ничек яхшырак итеп үтәргә һәм арттырып үтәргә, бюджет буенча билгеләнгән чараларга финанс вактында җибәреләме, акчаларны ничек итеп нәтиҗәлерәк һәм файдалырак тотарга?

Менә бу мәсьәләләр партия һәм совет оешмаларының көндәлек эшләре планында торырга тиеш.

1940 нчы елга Татарстан бюджеты 40 миллион сумнан артыграк күләмдә билгеләнә. Бу бюджетны үтәү республикабызда хуҗалык һәм культура төзелеше эшен тагын да үстерүне тәэмин итәр.

Татарстанның финанс органнары 1940 нчы елгы финанс бурычларын яхшырак үтәү өчен Башкыртстанның финанс органнары белән социалистик ярышка чыктылар.

Бурыч, түләүләрнең һәрбер төре буенча финанс йөкләмәләрен бик яхшы итеп үтәү өчен, барлык финанс работникларының һәм финанс активының масса күләмендәге ярышын эштә җәелдерүдән тора.

Партия һәм совет оешмалары актив булышлык иткәндә, бөтен совет җәмагатчелеге булышлык иткәндә без моңа ирешәчәкбез.

Чит илләрдә

ТАРТУДА ТӨЗЕЛГӘН ДОГОВОРНЫҢ 20 ЕЛЛЫГЫ

ТАЛЛИН, 2 февраль, (ТАСС). 1940 нчы елның 2 нче февралендә Тартуда тынычлык договорына кул куюга 20 ел тулды. Бу договор Советлар Союзы белән Эстония арасында яхшы күршеләрчә мөнасәбәтләргә һәм экономик элемтәләрне киңәйтүгә нигез салды. Договор Советлар республикасы тарафыннан Эстониянең дәүләт бәйсезлеген һәм аерымлыгын тануны раслады.

СССР белән Эстония арасында үзара ярдәмләшү турында 1939 нчы елның 28 нче сентябрендә кул куелган пакт һәм сәүдә килешүе СССР белән Эстония республикасы арасында Тарту договоры белән урнаштырылган дуслык мөнасәбәтләрен тагын да киңәйтү булып тора.

Тарту тынычлык договорына кул куюның 20 еллыгын, Эстония матбугаты Эстония республикасы тормышындагы гаять зур тарихи вакыйга дип билгеләп үтә. Үзәк һәм провинция газеталары бүген Тарту договорына һәм Эстония белән СССР арасындагы һәм башка илләр арасындагы мөнасәбәтләргә аның яхшы йогынты ясавына багышлап мәкаләләр басып чыгаралар. Газеталар Тарту договорының Көнбатыш Европа державалары договорларыннан аерымлыгын аеруча күрсәтеп үтәләр.

„Пявалехт“ газетасы договор турында: „Эстония—Россия тынычлык договоры Эстониянең 700 еллык тормышында гаять зур вакыйга булды“ ди. Аннары газета договорның ныклыгы өчен һәр төрле куркулар юкка чыкты дип күрсәтә.

Газета мәкаләне болай дип тәмам итә: „20 ел буена без Советлар Союзы белән тыныч яшибез һәм дусларча мөнасәбәтләрне киңәйтәбез“.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Үзәк Кытайда

Чжэцзян провинциясендә япон гаскәрләренең алга баруы кытайларның бик нык каршы торулары белән туктатылып тора. Японнар Линдуга таба (Сяошаньнан көнбатышта) килергә маташканнар иде, ләкин кире кайтарылдылар һәм чигенергә мәҗбүр булдылар.

Хубэй провинциясенең көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре Мачэнга һәм Сятяньгә таба алга баралар.

Төньяк Кытайда

Баотоу секторында (Суйюань провинциясе) кытай гаскәрләре, японнарның тылына удар ясау теләге белән, Хуанхэ елгасының төньяк ярында әйләнеп чыгу маневры үткәрделәр. Анда инде кытай гаскәрләренең колоннасы хәрәкәт итә. Бу колонна Улашань тауларыннан төньяктагы секторда японнарны кысрыклый.

Кытай гаскәрләре Гаопиннан көнчыгышта (Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлеше) берничә пункттан японнарны бәреп чыгардылар.

Көньяк Кытайда

31 нче январьда кытай гаскәрләре Наньнин—Биньян арасындагы шоссе юлы буйлап Наньнингә таба хәрәкәт итә башладылар. Утан пунктында (Наньниннән 30 километр төньяк-көнчыгышта) кытайлар японнарның бер полк гаскәрен чолгап алдылар һәм бетерделәр.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 2 февраль. (ТАСС). Германия информация бюросы белдерә: „Чикнең теге ягында, Саарлаутерннан көнбатышта герман күзәтүчеләре дошманның һөҗүмгә хәзерләнгән батальонын күрделәр һәм ул батальонга артиллериядән ут ачылды. Каршы якның һөҗүме кисәтелде. Германия авиациясе Англия өстендә үзенең күзәтү эшләрен дәвам иттерде һәм кыйммәтле мәглүматлар алуга ирешә“.

ПАРИЖ, 2 февраль. (ТАСС). Фронтның бөтен линиясендә кичә көн тыныч үтте, дип белдерелә. Рейн буенда атышулар барган.

БРЮССЕЛЬ, 2 февраль. (ТАСС) „Журналь“ газетасының 1 нче февральдәге хәрби күзәтүендә болай диелә: „Немецләр Саардан көнбатыштагы фронт участкысында ике тапкыр чыгыш ясадылар. Бер чыгыш 60 ка якын кешедән торган отряд тарафыннан үткәрелде. 50 кешедән торган отряд тарафыннан алып барылган икенче чыгыш җиддиерәк булды, чөнки артиллерия ярдәме белән үткәрелде. Башта немецларның артиллериясе үзенең утын безнең алдынгы постларыбызга юнәлдерде, ә соңыннан, ярдәмче көчләрнең килүенә комачаулау өчен, утны безнең тылга күчерде.

Немецләрнең бер самолеты Франциянең төньяк һәм көнчыгыш районнары өстендә очып йөрде“.

ЛОНДОН, 1 февраль. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенә караганда, 30 нчы январьда Германиянең су асты көймәсе Англиянең 5026 тонна авырлыгындагы „Вэклайт“ пароходын батырган һәм шуннан соң Англиянең оча торган көймәсе тарафыннан үзе дә тиз арада батырылган. Су асты көймәсенең командасыннан берничә кеше коткарылган.

БЕРЛИН, 2 февраль. (ТАСС). Швециянең 2.491 тонна авырлыгындагы „фрам“ дигән йөк пароходы Англия ярлары буенда баткан. Ул минага бәрелгән булырга кирәк дип уйлыйлар. 20 кешедән торган командасыннан бер кеше һәлак булган.

Норвегиянең „Фингал“ пароходы Шотландия ярлары буенда шартлау нәтиҗәсендә баткан. 11 кешедән торган командасы коткарылган.

БРЮССЕЛЬ, 2 февраль. (ТАСС). „Суар“ газетасының хәбәр итүенә караганда, январьның 20 сеннән 28 енә кадәр 29.101 тонна авырлыгындагы 13 сәүдә пароходы батырылган. Пароходларның берсе Англиянеке, икесе Франциянеке, 10 ысы—нейтраль илләрнеке булган.

АНГЛИЯ—ФРАНЦИЯ ПЛАННАРЫН ФАШ ИТҮ

СОФИЯ, 2 февраль. (ТАСС). Экономик „Стопански проблеми“ журналының шушы көннәрдә генә чыккан декабрь номерында Төньяк Европада Англия — Франция сугыш уты кабызучыларының эшен фаш итүче зур мәкалә иглан ителде. Журнал, СССР Финляндиягә каршы сугыш алып бармый, бәлки Финляндия Халык Хөкүмәте белән үзара ярдәмләшү турындагы договорны үтәп, Хельсинкидәге ак гвардиячеләр хөкүмәтенә каршы көрәшә дип күрсәтә. Мәкаләдә болай диелә: „Сугышка башка дәүләтләрне мөмкин кадәр күбрәк тарту һәм яңа төньяк Скандинавия фронты булдыру өчен сугышның мөмкин кадәр озаккарак сузылуы белән кызыксынучы кайбер дәүләтләр сугыш фронтын киңәйтергә телиләр“.

Аннары журнал, ак финнәр өчен булган коралны үзләренең территорияләре аркылы үткәрергә мәҗбүр итү өчен хәзер Швециягә һәм Норвегиягә ныклы басым ясала дип күрсәтә.

Япония парламентында

ТОКИО, 2 февраль. (ТАСС). Кичә парламентта финанс министре Сакурауциның 1940—41 нче бюджет елының бюджеты турындагы докладыннан соң баш министр, чит ил эшләре министре һәм финанс министре докладлары буенча фикер алышулар башланды.

Минсейто партиясенең лидеры Огава хөкүмәткә сорау белән чыкты. „Хөкүмәтнең политикасында иң әһәмиятле нәрсә Кытай мәсьәләсен хәл итү һәм Көньчыгыш Азиядә яңа тәртип урнаштыруга нигез итеп салынырга тиеш“ дип күрсәткәннән соң, Огава болай дип белдерде: „Япония Ван Цзин-вейнең яңа үзәк хөкүмәтен төзүгә токтарлык ясаучы Чан Кай-ши режимын бетереп кенә калмаска, бәлки шулай ук бу үзәк хөкүмәтне өченче державаларның да тануына ирешергә тиеш. Аннары Огава „Асама Мару“ белән булган инцидент уңае белән хөкүмәт нинди чаралар күрде дип сорау бирде.

Премьер Ионай Ван Цзин-вей хөкүмәте төзелгәч тә Япония хөкүмәтенең аны танырга, шулай ук бу хөкүмәтне өченче державаларда да танырга теләк булдырырга теләгәнлеген белдерде. Ионай болай диде: Япония Көнчыгыш Азиядә яңа тәртип төзүгә өченче державаларның токтарлык ясарга маташуларын кире каккан кебек, аларның һәр төрле катнашуларын да кискен рәвештә кире кага“.

Чит ил эшләре министре Арита „Өченче державалар белән мөнасәбәтләрне юлга салу Көнчыгыш Азиядә яңа тәртип төзү нигезендә барачак“ дип белдерде. АКШ хөкүмәтенең моны тулысынча аңлавы, Япония—Америка сәүдәсе мәсьәләләрен юлга салу өчен кирәкле нәрсә булып тора. Бу хөкүмәтләр икесе дә бу мәсьәләгә тыныч һәм салкын канлылык белән якын килә белергә тиешләр.

Арита шулай ук „Асама—Мару“ белән булган инцидентның,—япон халкының ачуын тудырган шушы инцидентның юлга салыначагына ышаныч белдерде.

Финанс министре Сакурауци болай диде: „Зарарлы инфляцияне булдырмау теләге белән ныклы экономия үткәреп хөкүмәт халыкның тормыш дәрәҗәсен нытыту өчен барлык чараларны күрергә уйлый“.

АНГЛИЯ—АМЕРИКА МӨНАСӘБӘТЛӘРЕ

НЬЮ-ЙОРК, 2 февраль. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия блокадасыннан риза булмаучы Америка җәмагатьчелек фикрен тынычландыру өчен, Англия хөкүмәте күп кенә чаралар күрә.

Алынган мәглүматларга караганда, Англия хөкүмәте Америка пароходларын тикшерүне тәгәлләү өчен Канадада контроль пункты төзү мәсьәләсен дә карый. Тикшерүне хәрби зоналарда тәгәлләүгә караганда мондый тәртип иң уңай булуга карамастан, дәүләт департаментының вәкилләре, мондый тәртип зур расходлар тотуга сәбәп булачак, дип күрсәтәләр, чөнки Америка судноларына үзләренең курсларыннан берничә йөз милгә читкә китәргә туры киләчәк. Шуның өстенә Канадада контроль пункты төзү, анда Германия су асты көймәләренең килүенә сәбәп булуы мөмкин.

Агентлык, контроль пунктлары кайда гына төзелсә дә, АКШ аларны рәсми рәвештә танырга теләми, дип күрсәтә. АКШ, сугышучы дәүләтләрнең властьлары Америка пароходларын бары тик ачык диңгездә генә карарга тиешләр дип саный.

Шау-шу астында

Социал-демократ:
— Безгә көнчыгыштан пожар куркынычы бар. В. Персон рәсме. (ТАСС фото-клишесе).

РӘСЕМДӘ: Фрунзе исемендәге хәрби Академиядә укучы, Советлар Союзы Геройлары Г. А. Батыршин һәм И. Д. Чернопятко иптәшләр Молотов районының (Казан) 16 нчы номерлы балалар бакчасында кунакта.

В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

БӘЙРӘМ АЛДЫ ЯРЫШЫ ҺӘМ АНЫҢ БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Казан пехота училищесе коллективы Кызыл Армиянең XXII еллыгын зур уңышлар белән каршы алырга хәзерләнә. Училищенең барлык подразделениеләре дә Кызыл Армиянең XXII еллыгы исемендәге социалистик ярышка кушылдылар. Подразделениеләр, бүлекләр һәм курсантлар арасында индивидуаль ярыш договорлары төзелде. Аларның үтәлеше көн саен тикшерелә һәм ярышның нәтиҗәләре махсус такталарда яктыртыла.

Ярыш нәтиҗәсендә училище хәрби-политик хәзерлек өлкәсендә зур уңышларга ирешә. Командиры иптәш Афанасьев булган подразделение ике елдан бирле хәрби һәм политик хәзерлекнең барлык төрләре буенча училищедә беренче урынны алып килә. Училищенең һәм округның күчмә кызыл байрагын ике елдан бирле бу подразделение үзендә саклый һәм киләчәктә дә үзендә саклап калу өчен нык көрәшә. Күптән түгел булган зачетларның нәтиҗәләре моңа тулы ышаныч бирәләр. Подразделение зачетларда бик яхшы күрсәткечләр бирүгә ирешә. Станоклы пулеметтан ату буенча курсантларның 93 проценты яхшы—отлично билгесе, винтовкадан ату буенча 97 проценты яхшы—отлично билгесе алдылар. Политик хәзерлек өлкәсендә дә уңышлар зур. Курсантларның 93 проценты политик хәзерлектән яхшы—отлично билгесе алды. Хәрби-политик хәзерлек отличниклары Шанcов, Бутрик, Тарханов, Козлов, Честняков, Фрошин һәм күп кенә башка иптәшләр училищенең почет тактасына язылдылар.

Командиры иптәш Тверской булган подразделение дә ярыш нәтиҗәсендә яхшы күрсәткечләр бирүгә ирешә. Бу подразделение винтовкадан 1 нче упражнениене отличнога үтәде. Сугышчылардан Данилов, Белкин һәм Колесов иптәшләр мөмкин булган 30 очкодан 29 ар очко, ә башкалар 28 әр очко бирделәр.

Командиры иптәш Остряков булган подразделениенең яш сугышчылары винтовкадан беренче упражнение үткәрделәр. Сугышчыларның 90 проценты бу упражнениене яхшы—отлично һәм калганнары канәгатьләнерлек билгесенә үтәделәр. Политик хәзерлектән беренче тема буенча подразделение отлично билгесе алды.

Училищенең барлык подразделениеләрендә дә Кызыл Армия бәйрәменә зур хәзерлек бара. Ленин бүлмәләре яңадан пөхтә итеп җиһазландырылалар. Халыкларның бөек юлбашчысы иптәш Сталинның Кызыл Армияне төзүдәге роле һәм көрәш тарихы Ленин бүлмәләрендә тулы итеп чагылдырылачак.

Училище күләмендә физкультура-чаңгы ярышлары үткәрелә. Ярышта өстен чыгучыларга бүләкләр хәзерләнә.

Начсостав хатыннарының ату командасы узган ел гарнизон күләмендә беренчелекне алып, гарнизонның күчмә кызыл байрагы белән, команданың членнары Кудакаева, Кузьмина, Острякова һәм башка иптәшләр грамоталар белән бүләкләнгәннәр иде. Хәзер бу команда гарнизон күләмендә үткәреләчәк ярышта катнашырга хәзерләнә.

Училищедә социалистик ярыш көннән-көн киң җәелә, хәрби-политик хәзерлек отличникларының сафлары өзлексез үсә. Училище коллективы данлыклы Кызыл Армиянең XXII еллыгын югары уңышлар белән каршылау өчен барлык тармакларда да эшне киң җәелдерә.

Г. Сафиуллин.

Хәрби эшне өйрәнәләр

Чаллы районының Молотов исемендәге колхозында, фельдшер иптәш Хөсәенев инициативасы белән, хәрби эше өйрәнү түгәрәге төзелгән иде. 31 колхозчы (аларның 23 е допризывниклар) ГСО значогы алды.

„Туры Юл“ колхозында Осоавиахимның башлангыч оешмасы зур эш алып бара. Граната ыргытучылар һәм Ворошиловча атучылар түгәрәгенә 15 кеше йөри.

***

Столбище районында Кызыл Армиянең 22 еллыгын үткәрүгә хәзерлек башланды. Осоавиахимның район советы һәм партия райкомының хәрби бүлеге инициативасы белән агитбригадалар оештырылды. Бу бригадалар колхозларда оборона түгәрәкләренең эшләрен юлга салуда Осоавиахимның башлангыч оешмаларына булышлык итәчәкләр.

Кызыл Армиянең 22 еллыгына хәзерлеккә РОКК оешмалары да актив катнашалар. РОКК ның Никольское авылындагы башлангыч оешмасы 20 кешене ГСО значкисты итеп хәзерләде. Столбище больницасы янында ГСО значогына норма тапшыру түгәрәге оештырылды. Аңа допризывниклардан 30 кеше йөри. Столбище һәм Көек авылларындагы урта мәктәпнең югары классларында укучылар өчен Ворошиловча атучылар түгәрәкләре оештырылды.

Кызыклы күргәзмә

Казан Медицина институтының 125 еллыгы уңае белән, бу институтның тарихына һәм хәзерге көненә багышлап оештырылган күргәзмә үзендә гаять бай эчтәлекле материалларны туплаган. Укучы яшьләр, меңләгән хезмәт ияләре, фән һәм дәүләт эшлеклеләре күргәзмәне зур кызыксыну белән карыйлар. Чөнки күргәзмә үзенең тарихи документлары, кызыклы саннары, фәнни һәм политик әһәмияткә ия булган фактлары белән, һич шиксез, бик күп нәрсәләр турында сөйли, бик күпне аңлата.

Бөек Октябрь Социалистик Революциясеннән соң фән, аерым алганда, медицина фәне бөтенләй яңа мөмкинлекләр таба. Бу бөек яңару процессы берничә төрле юл белән бара. Беренчедән, фәнне яңа кешеләр, нык куллы, таза характерлы хезмәт ияләре яулап алалар һәм алар үзләре белән яңа традицияләр алып киләләр. Икенчедән, социалистик дәүләт фәнне турыдан-туры үз канаты астына ала, аның үсүе, чәчәк атуы өчен куәтле чаралар күрә, фәнне яңа, моңа чаклы һич тә күрелмәгән материал базаларга куя.

Бу куәтле яңару процессы медицина институты тарихында да бик ачык чагыла. Медицина фәненең яңа тармаклары гражданлык хокукы алалар. Әнә шундый яңа тармаклардан берсе—социал гигиена тармагы. Дөрес, кайчандыр, моннан күп еллар элек тә, бу турыда уйлаучылар булгалаган. Врач һәм актив җәмагат эшлеклесе Петров, Казан университетының медицина факультеты укытучылары Осипов, Молессонлар бу юнәлештә уйларга, „медицинага аңлы җәмагатчелекне катнаштыру“ буенча кайбер нәрсәләр эшләргә батырчылык итеп карыйлар. Ләкин хосуси милекчелеккә корылган дөньяда алар җилкәнсез караб хәлендә калалар, аларның омтылышлары коры омтылыш булудан узмый. Бары тик Бөек Октябрь Революциясеннән соң гына социал гигиена үзенә киң мәйдан таба, 1922 нче елны Москва медицина институтында, 1923 нче елда Казан Медицина институтында социал гигиена кафедралары оештырылып, эшкә башлыйлар.

Яки менә хезмәт гигиенасы кафедрасын алыйк. Бусы әле бөтенләй яшь. Ул бары тик 1932 нче елны гына оештырылган. Ләкин, яшьлегенә дә карамастан, ул инде тәҗрибәгә баеп өлгергән, социалистик производствога үзенең законнарын—хезмәт гигиенасы законнарын күп кенә тараткан.

Күргәзмәдә бик кызыклы бүлекләрнең берсе—оборона дисциплиналары кафедрасы. Монда инде хәзерге сугыш техникасының барлык „серләре“н дә табарга була. Күргәзмәдә булучылар бу бүлектән аеруча тулы канәгатьләнү тойгысы алалар.

2 нче февральдә бу күргәзмәдә Татарстан республикасының партия һәм хөкүмәт вәкилләре булдылар. Монда ВКП(б) Өлкә Комитеты секретарьлары Алемасов, Матвеев, Долотказин, Татарстан Верховный Советы Президиумы председателе Динмөхәмәтов һәм Халык Комиссарлары Советы председателе Тынчеров иптәшләр бар иделәр. Алар күргәзмәдән яхшы һәм тулы тәэсир калганлыгын белдерделәр.

Ф.

СУД

СПЕКУЛЯНТЛАР

Казан шәһәре, Киров районының 2 нче участкы халык суды 1 нче февральдә Рәхимә Әлмөхәметова һәм Хәерниса Юсупкулова дигән спекулянтларның эшен карады. Алар Советлар Союзының төрле шәһәрләренә барып киң куллану товарлары алып кайтканнар һәм аларны спекуляция бәясеннән сату белән шөгыльләнгәннәр. Халык суды Әлмөхәметованы һәм Юсупкулованы 5 әр елга ирекләреннән мәхрүм итәргә хөкем итте.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗМЕХКОМБИНАТНЫҢ
Н. К. Крупская исемендәге
ФЗУ МӘКТӘБЕ
мех әйберләре тегү буенча югары квалификацияле тегүчеләр хәзерләү өчен
УКУЧЫЛАР АЛА
УКУ СРОГЫ 1 ЕЛ.
Мәктәптә 17—18 яштәге һәм 6—7 класс күләмендә белемле хатын-кызлар алыналар.
Гариза белән бергә, керүченең белеме һәм яше турында белешмәләр бирелергә тиеш.
Мәктәпкә алынганнарга, аларның академик һәм практик өлгерешләренә карап, айга 70 сумнан 130 сумга кадәр стипендия бирелә.
Күрсәтелгән документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Яңа бистә, Кечә Ямашев урамы, 71. Телефон 44—14.
182—4—1

Үзәк Промышленность Төзелеше Эшчеләре союзының Татарстан Өлкә —Комитеты бетерелү уңае белән,— ликвидация комиссиясе төзелде.
Үзәк Промышленность Төзелеше Эшчеләре союзының Татарстан Өлкә Комитетына карата булган дәгваларны түбәндәге адрес буенча ликвидком 1940 нчы ел, 10 нчы февральгә кадәр генә кабул итә.
Күрсәтелгән сроктан соң бирелгән дәгвалар каралмаячак.
203—1 ЛИКВИДКОМ.

ЗӨЯ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ — ТЕХНИКУМЫНА —
1940 нчы уку елы өчен
ӨСТӘМӘ РӘВЕШТӘ
УКУЧЫЛАР АЛУ
шушы ел, 15 нче февральгә кадәр
ДӘВАМ ИТӘ
178—1

„ТРАНСЭНЕРГОКАДР“ НЫҢ
КАЗАН АВТОМӘКТӘБЕ
производстводан аермыйча укытып, 3 нче класс шоферлардан II һәм I нче класс шоферлар хәзерләү буенча шушы ел 10 нчы — февральдән —
КУРСЛАР АЧА
Курсларга предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алына. Казан, Банк урамы, 15. Телефон 38—52.
176—2—1

Татарстан Юллар Идарәсенең проэктлар һәм техник эзләнүләр конторасы техник эзләнү эшләре,
шулай ук авто-атлы транспорт юлларының, подъездларның һәм аларның корылышларының
проэктларын һәм сметаларын төзү эшләре үти.
Казан, Комсомол урамы (Кабан күленең сул ягы), 42. Телефон 12—47.
170—1

Үзәк Промышленность Төзелеше Эшчеләре союзының Татарстан Өлкә Комитеты
шушы ел, 1 нче февральдән
БЕТЕРЕЛДЕ
Үзәк Промышленность Төзелеше Эшчеләре союзының Татарстан Өлкә Комитетына карата булган барлык дәгваларны 1940 нчы ел, 10 нчы февральгә кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Казан, Комлев урамы, Хезмәт Сарае, 57 нче бүлмә. ЛИКВИДКОМ.
202—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
5 нче февральдә
КЫЮ КЫЗЛАР
Талон 108.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
4 һәм 5 нче февральдә
МАСКАРАД
Талон бүген 92.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Телефоннар: 30—78 һәм 29—04
Бүген 4 нче февральдә
КАЧКЫН
Талон 74.
Рольләр яш артистлар тарафыннан башкарыла
Кич 9 сәгатьтә башлана.

КИРӘК:
„Торгречтранс“ның Казан конторасына, бүлекләр һәм базалар өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, шулай ук ЭКОНОМИСТЛАР, КАРТОТЕКАЧЫ һәм ИНСТРУКТОР-КУЛИНАР. Куйбышев урамы, 7 (ишек алдыннан керергә). 108—3—3

Автокузов заводына (Эшчеләр бистәсе, Набережный урам, 11) КОНСТРУКТОР, ЯЗУ МАШИНАСЫНДА ЭШЛӘҮЧЕ МАШИНИСТКА, БУХГАЛТЕР-ФИНАНСИСТ, МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЫ, БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, НОРМАЛАУЧЫ, ТЕХПРОПАГАНДА БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕ, ХЕЗМӘТ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ, АГАЧ һәм БУЯУ МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЕНЧА ТЕХНОЛОГЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча.
181—2—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
БҮГЕН һәм һәр көн
Москва 4 нче труппасының
— соңгы гастрольләре —
ПОПУЛЯР КОМИК, һӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик — труппасы белән —
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН һӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	БАЛТЫКЧЫЛАР
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	БӨЕК БҮЛӘК
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ФЕДЬКА Кич ТРАКТОРЧЫЛАР. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (1 нче сериясе)
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ

Казан Ит комбинатына ПЛАННАР БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ һәм ХЕЗМӘТ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ кирәк. Казан, Тимер юл урамы, 3. 116—2—2

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А —707 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 455.